СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.2, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 2 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

От «18» сентября 2019г. № 1-45

## Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләнгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Җөри авылы, Заречный урамы; Түбән Шүләңгер авылы, Совет урамы; Комаровка авылы, Нагорный урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, түләү буенча эш килешүе);
- Уткино, урта Шүләңгер авылларында җирле әһәмияттәге юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- җәйге вакытта Березовая Поляна бистәсендәге территорияне чабу.

« ӘЙЕ »    « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге башлыгы Е.М.Михайловага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләнгер авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе    Е.М.Михайлова.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НИЖНЕШАНДЕРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001059